2024 елнын 23 октябрендә Рузаевканын 10 нчы мәктәп музеен оештыручы Фәризә Рәхим кызы Киселева инициативасы белән «Россия Герое Сергей Иванович Вандышевнын тормышы һәм язмышы» дигән патриотик форумы vткән. Геройнын 105-еллыгына багышланган. Бу - Рузаевка районы Ветераннар советынын һәм 10 нчы мәктәпнен уртак чарасы. Форум эшендә мәртәбәле кунаклар катнашкан: Фәризә Рәхим кызы китап турында сойләгән, Людмила Степановна Сандина фәнни-тикшеренv эше - «Трибунал һәм Вандышевнын Алтын Йолдызы» монографиясе якташыбыз, Россия Герое, очучы - штурмовик Сергей Вандышев тормышы vрнәгендә чын патриотлар тәрбияләvдәге роле турында ишеттергән.
Концлагерьларда җәһәннәм газаплары аша vтеп, С.И.Вандышев тиндәшсез батырлык, ныклык һәм кыюлык кvрсәткән батыр. Кешелексез шартларда ана халыкларнын туганлыгы, якташлары-очучылар Михаил Петрович Девятаев, Василий Николаевич Грачев, Алексей Тимофеевич Воронинннын нык дуслыгы ярдәм иткән. Тугызынчы мәктәпнен «Адым артыннан адым» Рузаевка эзләv отряды житәкчесе Илюшкина Валентина Михайловна кин колачлы чараны оештыручы Фәризә Рәхим кызы Киселевага һәм форумны алып баручы Галия Наил кызы Невлютовага рәхмәтләрен дә белдергән. Форумда катнашучыларнын барысы да укучыларны тәрбияләvнен моһимлеген, кочен билгеләп vт-кәннәр. «Мондый патриотик форумнарны барлык мәктәпләрдә сис-темалы рәвештә уздырырга кирәк» дигән резолюция дә кабул иткәннәр.